РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«30» декабрь 2021 с. Тюлячи № 333

Теләче муниципаль районында 2022 елга балалар
һәм яшьләр ялын оештыру турында

Район Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенең 2021 елның 21 декабрендәге 204 номерлы хатын карап, балачакны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон,Татарстан Республикасы министрлар Кабинетының «Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган «2019-2025 елларга «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районында 2022 елга балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия төзергә һәм аның составын 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.

2. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

- 2 номерлы кушымта нигезендә 2022 елга балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча район ведомствоара комиссия турында Нигезләмә;

- 3 номерлы кушымта нигезендә, Теләче муниципаль районында 2022 елга балалар һәм яшьләр ялын оештыру программасы;

- 4 номерлы кушымта нигезендә барлык төр лагерьларга юллама бирү турында гариза формасы;

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Теләче муниципаль районындагы социаль яклау бүлегенә (Галимова Ф.М.), Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә (Ибраһимов З.З.), МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» нә (Карпова Н. В.) беренче чиратта ятим балаларның, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның, инвалид балаларның, аз керемле, күп балалы һәм тулы булмаган

гаиләләрдәге балаларның, качаклар һәм күченеп китәргә мәҗбүр булган гаиләләрдәге балаларның ялын оештыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. ДАССУ «Теләче үзәк район хастаханәсе» (Галиуллин И.И.) сәламәтләндерү лагерьларын гамәлдәге законнар нигезендә медицина кадрлары белән комплектларга, сәламәтләндерү лагерьларының төп эш урыны буенча хезмәт хакын саклауны тәэмин итәргә, сәламәтләндерү лагерьларында эшләүчеләрне бердәм үрнәктәге медицина кенәгәләренә кертү өчен түләмичә медицина тикшерүе уздыруны тәэмин итәргә; беренче чиратта аз тәэмин ителгән, күп балалы, тулы булмаган гаиләләрдән хроник авырулар белән интегүче балаларны савыктыру һәм дәвалауны оештырырга, балалар ялын һәм дәвалауны оештыручы учреждениене дару препаратлары белән тәэмин итүне тәэмин итәргә.

5. Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсе Саба һәм Теләче муниципаль районнары буенча районара ОНД начальнигы (Галимуллин А. Р.) тәкъдим итәргә:

- Теләче муниципаль районы территориясендә җәйге сәламәтләндерү лагерьларының барлык төрләрендә дә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне күзәтүне тәэмин итәргә;

- лагерьларда балаларга хезмәт күрсәтүгә җәлеп ителгән барлык хезмәткәрләр белән балаларның ял һәм сәламәтләндерү вакытында куркынычсызлык техникасы, гадәттән тыш хәлләрне һәм террорны кисәтү буенча инструктажлар үткәрергә.

6. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасына (Яхин Р. Р.) тәэмин итәргә:

- гамәлдәге закон нигезендә балалар сәламәтләндерү лагерьларын финанслау;

- бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту.

7. МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» нә (Карпова Н.В.) һәм Теләче муниципаль районы Башкарма комитетынын яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә (Ибраһимов З.З.) балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча «Җәй» республика балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруның дәүләт учреждениесенә оператив һәм йомгаклау мәгълүматын бирергә. Бюджет акчаларын үтәү турында финанс хисапларын вакытында тапшыруны тәэмин итәргә.

8. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлегенә (Ихсанов Д.С.) күчмә китапханә эшен сәламәтләндерү лагерьларында оештырырга.

9. Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче муниципаль районы буенча бүлекчәсенә (Зарипов и.с.) сәламәтләндерү лагерьлары территорияләрен саклауны, сәламәтләндерү лагерьлары территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны һәм ЮХИДИ белән берлектә балаларны сәламәтләндерү учреждениеләренә илтү һәм алып кайту өчен автобусларны озата баруны тәэмин итү.

10. Билгеләргә, түбәндәгеләрне:

- Теләче муниципаль районында 2022 елга балалар һәм яшьләр ялын оештыру Татарстан Республикасы бюджеты, Теләче муниципаль районы бюджеты, ата-аналар кертеме, бюджеттан тыш чыганаклар, законнар белән тыелмаган башка чыганаклар хисабына тормышка ашырыла;

- сәламәтләндерү учреждениеләрендә сменаларның озынлыгы - 18, 21 көн, көзге чорда-7 көн тәшкил итә;

- лагерьларда балалар һәм яшьләрнең ял иткән өчен ата-аналар түләве күләме балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга норматив чыгымнарның 15% күләмендә билгеләнә, әмма ял итү төренә карап юлламаның факттагы бәясеннән 50% артмаска тиеш.

10.1. Юллама өчен ата-аналар түләве алынмый:

- Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлеге аша бүленә торган;

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы, Татарстан Республикасы спорт министрлыгы республика, төбәкара, округ, бөтенроссия һәм халыкара ярышлар, конкурслар, олимпиадалар һ. б. җиңүчеләргә һәм призерларга бүләк итеп бирелә торган республика профильле сменаларына;

- конкурслар, олимпиадалар һ. б. җиңүчеләргә һәм призерларга бүләк сыйфатында бирелә торган;

11. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «30» 12 2021ел №333 карарына 1 номерлы кушымта

**Теләче муниципаль районында 2022 елда балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча район ведомствоара комиссиясе составы**

Комиссия рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Гыйниятуллин Д.С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |

Комиссия рәисе урынбасарлары:

| | | |
|---|---|---|
| Карпова Н.В. | - | МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» башлыгы; |
| Ибраһимов З. З. | - | район Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы. |

Комиссия сәркатибе:

| | | |
|---|---|---|
| Гарипова Т. А. | - | район Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге баш белгече. |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Галимова Ф. М. | - | ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Теләче муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Яхин Р. Р. | - | район Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| Галимҗанов А. М. | - | ДКУ «Теләче муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» директоры (килешү буенча); |
| Зарипов И. С. | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлекчәсе башлыгы (килешү буенча); |
| Галиуллин И. И. | - | «Теләче үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча); |
| Ихсанов Д. С. | - | район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы; |
| Җәләев И. И. | - | МБУ «Олимп» яшьләр үзәге директоры»; |
| Галимуллин А. Р. | - | Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР КЭИ ПЭ Саба һәм Теләче муниципаль районнары буенча районара күзәтчелек эше бүлеге башлыгы (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «30» 12 2021 №333 карарына 2 номерлы кушымта

**Теләче муниципаль районында 2022 елда балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча район ведомствоара комиссиясе турында Нигезләмә**

1. 2022 елга балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча район ведомствоара комиссиясе (алга таба - Комиссия) Теләче муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ял итү программасын тормышка ашыру максатыннан төзелде һәм район Башкарма комитетының эшче органы булып тора.

2. Комиссияне ике урынбасары булган рәис җитәкли. Комиссия составына район Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, Теләче муниципаль районында министрлыклар һәм ведомстволарның территориаль органнары вәкилләре керә.

3. Комиссия үз эшчәнлегендә гамәлдәге законнарга һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

- район Башкарма комитеты бүлекләре, министрлыкларның, ведомстволарның территориаль органнары, төрле фондлар, акционерлык җәмгыятьләре, барлык милек формасындагы предприятие һәм берләшмәләр, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген координацияләү;

- район Башкарма комитеты бүлекләре, предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре эшчәнлеген анализлау, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча комиссия утырышларында аларның җитәкчеләренең хисапларын тыңлау, үз вәкаләтләре кысаларында тәкъдимнәр һәм карарлар кабул итү, аларның үтәлешен тикшерү;

- 2022 елга Теләче муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру һәм финанслау мәсьәләләрен карау;

- 2022 елга Теләче муниципаль районында балалар һәм яшьләр ял итү программасын тормышка ашыруны контрольдә тоту.

5. Комиссия хокуклы:

- балалар һәм яшьләр ялын оештыру мәсьәләләре буенча район Башкарма комитеты Җитәкчесенә тәкъдимнәр әзерләргә һәм кертергә;

- балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы министрлыклардан, ведомстволардан, предприятиеләрдән, оешмалардан, учреждениеләрдән гамәлдәге законнар нигезендә үз компетенцияләренә караган документларны, белешмәләрне, материалларны соратып алырга;

- балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмә документларның үтәлешен контрольдә тотарга.

6. Аның компетенциясе кысаларында кабул ителгән Комиссия карарлары барлык җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәлергә тиеш, район предприятиеләре, оешмалары, учреждениеләре өчен, аларның милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, муниципаль булмаган килеш, тәкъдим итү характерына ия.

7. Комиссия карарлары комиссия әгъзалары утырышында катнашучы гади күпчелек тавыш белән кабул ителә, утырыш беркетмәләре белән рәсмиләштерелә, алар комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

8. Комиссия утырышы аның составының 2/3 өлеш әгъзасы булса, хокуклы дип санала.

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «30» 12 2021 №333 карарына 3 номерлы кушымта

# 1. Программа Паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның атамасы | Теләче муниципаль районында 2022 елга балалар һәм яшьләр ял итү программасы (алга таба-Программа) |
| Муниципаль заказчы | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Теләче районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| Программаны төп башкаручылар | - Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба-ТМР БК);<br>- район Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;<br>- МКУ «Район Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»;<br>- район Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе;<br>- ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Теләче районындагы социаль яклау идарәсе;<br>- район Башкарма комитетының мәдәният бүлеге;<br>- Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлекчәсе;<br>- ДАССУ «Теләче үзәк район хастаханәсе» |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | - балачакны яклау, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру, аларның мәшгульлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыру;<br>- балалар һәм яшьләр ялы өчен шартлар тудыру;<br>- авыр тормыш хәлендә булган балаларның һәм гаиләләрнең тормыш-көнкүрешен яхшырту һәм имин булмаган проблемаларын хәл итү;<br>- балалар һәм яшьләр ялы, балалар һәм яшьләр туризмы һәм спортның төрле формаларын үстерү;<br>- балалар һәм яшьләрнең ял итү инфраструктурасын саклау һәм ныгыту |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2022 ел |
| Программа чаралары исемлеге | 1. Иҗади яки социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләре өчен стационар лагерьларда профильле сменалар оештыру.<br>2. Авыр тормыш хәлендә һәм социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балаларның бушлай ялын оештыру.<br>3. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге ял лагерьларында сменаларны оештыру. |

| | |
|---|---|
| | 4. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерьларда сменалар оештыру.<br>5. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары өчен хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар оештыру |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2022 елга Программаны финанслауның гомуми күләме 2398,49 мең сум тәшкил итә,( шул исәптән АТХ -196,7 мең сум)<br>шул исәптән:<br>- Татарстан Республикасы бюджетыннан балалар һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруга 2061,90 мең сум күләмендә субсидияләр;<br>- балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты субсидияләре 1,0 мең сум,<br>- ата-аналар акчасы 314,79 мең сум.<br>- Теләче муниципаль районы бюджеты акчасы 20,8 мең сум. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 7 яшьтән алып 16 яшькә кадәрге балаларны каникул чорында 45 процenttан да ким булмаган ял итү рәвешләре белән тәэмин итү.<br>Барлык программа чаралары нәтиҗәләре буенча сәламәтләндерү эффектының кимендә 90 проценты дәрәҗәсенә ирешү.<br>Тормышка ашырылган чараларның сыйфаты һәм нәтиҗәлелеге.<br>Авыр тормыш хәлендә калган балаларның хәлен яхшырту |

## 2. Әлеге программа кысаларында хезмәт күрсәтү күләмнәренең расланган нормативлары нигезендә үткәрелә торган чаралар

| № т/б | Чаралар исеме | Уздыру вакыты | Кеше саны | Оештыру өчен җаваплы (башкаручы) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Көндезге лагерьда сменаларны оештыру (мәктәп яны) | | | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге |
| | - җәйге чорда | 01.06.2022 - 21.06.2022 (Теләче УГББМ 1-21 июль 2022) | 280 | |
| | - көзге каникуллар чорында | 1-7 ноябрь 2022 | 150 | |
| 2. | Хезмәт һәм ял лагерында сменаны оештыру | 01.06.2022 - 18.06.2022 ел | 30 | |
| 3. | Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерьда сменалар оештыру | Конкурс нәтиҗәләре буенча 21 көн | 20 | Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 4. | Стационар лагерьда профильле сменалар оештыру | Конкурс нәтиҗәләре буенча 18 көн | 20 | |
| | | Конкурс нәтиҗәләре буенча 7 көн | 20 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5. | Авыр тормыш һәм социаль куркыныч хәлдә булган балаларның бушлай ялын оештыру.<br>- профилактик исәптә торучы балалар өчен палаткалы лагерьда махсуслаштырылган смена;<br>- стационар лагерьда смена | Ел дәвамында<br><br>7 көн<br><br>21 көн<br><br>7 көн | <br><br>10<br><br>5<br><br>5 | |
| | Барлыгы: | | 540 | |

### 3. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге ял лагерьларында сменаларны оештыру

| Лагерьны оештыру өчен база (мәктәп) | Үткәрү территориясе | Кеше саны* | Көн саны* | Бер көнгә бер бала өчен урын | Юлламаның норматив бәясе | ТР бюджетыннан субсидияләр** | Ата-аналар кертеме** | Җирле бюджеттан субсидияләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Җәйге чорда | | | | | | | | |
| Алан УГББМ | Алан авылы | 10 | 21 | 187,30 | 39333,00 | 33098,72 | 5899,95 | 334,33 |
| Олы Мишә УГББМ | Олы Мишә авылы | 15 | 21 | 187,30 | 58999,50 | 49648,08 | 8849,93 | 501,49 |
| Олы Нырсы УГББМ | Олы Нырсы авылы | 10 | 21 | 187,30 | 39333,00 | 33098,72 | 5899,95 | 334,33 |
| Олы Мәтәскә УГББМ | Олы Мәтәскә авылы | 15 | 21 | 187,30 | 58999,50 | 49648,08 | 8849,93 | 501,49 |
| Югары Кибәхуҗа УГББМ | Югары Кибәхуҗа авылы | 12 | 21 | 187,30 | 47199,60 | 39718,46 | 7079,94 | 401,20 |
| Сауш УГББМ | Сауш авылы | 10 | 21 | 187,30 | 39333,00 | 33098,72 | 5899,95 | 334,33 |
| Иске Җөри УГББМ | Иске Җөри авылы | 18 | 21 | 187,30 | 70799,4 | 59577,69 | 10619,91 | 601,79 |
| Теләче УГББМ | Теләче авылы | 140 | 21 | 187,30 | 550662,00 | 463382,07 | 82599,30 | 4680,63 |
| Шәтке УГББМ | Шәтке авылы | 20 | 21 | 187,30 | 78666,00 | 66197,44 | 11800,00 | 668,56 |
| Баландыш ТГББМ | Баландыш авылы | 10 | 21 | 187,30 | 39333,00 | 33098,72 | 5899,95 | 334,33 |
| Үзәк УГББМ | Үзәк поселогы | 20 | 21 | 187,30 | 78666,00 | 66197,44 | 11800,00 | 668,56 |
| **Барлыгы:** | | **280** | | | **1101324,0** | **926764,14** | **165198,60** | **9361,25** |
| Калган чорда | | | | | | | | |
| Алан УГББМ | Алан авылы | 10 | 7 | 187,30 | 13111 | 12979,89 | 1966,65 | 131,11 |
| Олы Мәтәскә УГББМ | Олы Мәтәскә авылы | 10 | 7 | 187,30 | 13111,00 | 11032,91 | 1966,65 | 111,44 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Олы Мишә УГББМ | Олы Мишә авылы | 10 | 7 | 187,30 | 13111,00 | 11032,91 | 1966,65 | 111,44 |
| Югары Кибәхуҗа УГББМ | Югары Кибәхуҗа авылы | 10 | 7 | 187,30 | 13111,00 | 11032,91 | 1966,65 | 111,44 |
| Иске Җөри УГББМ | Иске Җөри авылы | 10 | 7 | 187,30 | 13111,00 | 11032,91 | 1966,65 | 111,44 |
| Теләче УГББМ | Теләче авылы | 70 | 7 | 187,30 | 91777,00 | 77230,34 | 13766,55 | 780,10 |
| Шәтке УГББМ | Шәтке авылы | 10 | 7 | 187,30 | 13111,00 | 11032,91 | 1966,65 | 111,44 |
| Үзәк УГББМ | Үзәк поселогы | 10 | 7 | 187,30 | 13111,00 | 11032,91 | 1966,65 | 111,44 |
| Олы Нырсы УГББМ | Олы Нырсы авылы | 10 | 7 | 187,30 | 13111,00 | 11032,91 | 1966,65 | 111,44 |
| **Барлыгы:** | | **150** | | | **196665,00** | **165493,59** | **29499,75** | **1671,65** |

## 4. Хезмәт һәм ял лагерында сменаны оештыру

| Лагерьны оештыру базасы | Лагерьны үткәрү территориясе | Кеше саны* | Көн саны* | Койка-1 бала көне | Юлламаның норматив бәясе | ТР бюджетыннан субсидияләр** | Ата-аналар кертеме** | Җирле бюджеттан субсидияләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Алан УГББМ | Алан авылы | 10 | 18 | 187,30 | 33714,00 | 33376,86 | 0 | 337,14 |
| Олы Мәтәскә УГББМ | Олы Мәтәскә авылы | 10 | 18 | 187,30 | 33714,00 | 33376,86 | 0 | 337,14 |
| Шәтке УГББМ | Шәтке авылы | 10 | 18 | 187,30 | 33714,00 | 33376,86 | 0 | 337,14 |
| **Барлыгы:** | | **30** | | | **101142,00** | **100130,58** | 0 | **1011,42** |

**5. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерьларда сменалар оештыру**

| Стационар БСЛ атамасы | Үткәрү территориясе | БСЛ балансга тотучының исеме | Кеше саны* | Көн саны* | Бер көнгә бер бала өчен урын | Юлламаның норматив бәясе 100% | Бюджеттан субсидияләр** | Ата-аналар кертеме** | Башка чаралар (җирле бюджет)** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Үткәрелгән ачык аукцион нәтиҗәләре буенча | | | | | | | | | |
| Конкурс нәтиҗәләре буенча | | - | 20 | 21 | 876,05 | 367941,00 | 369622,35 | 55191,15 | 3127,49 |

**6. Стационар лагерьларда профильле сменалар оештыру**

| Стационар БСЛ атамасы | Үткәрү территориясе | БСЛ балансга тотучының исеме | Кеше саны* | Көн саны* | Бер көнгә бер бала өчен урын | Юлламаның норматив бәясе | Бюджеттан субсидияләр** | Ата-аналар кертеме** | (җирле бюджет) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Үткәрелгән ачык аукцион нәтиҗәләре буенча | | | | | | | | | |
| Конкурс нәтиҗәләре буенча | | - | 20 | 18 | 865,35 | 311526,00 | 262149,13 | 46728,90 | 2647,97 |

**7. Стационар лагерьларда профильле сменалар оештыру**

| Стационар БСЛ атамасы | Үткәрү территориясе | БСЛ балансга тотучының исеме | Кеше саны* | Көн саны* | Бер көнгә бер бала өчен урын | Юлламаның норматив бәясе | Бюджеттан субсидияләр** | Ата-аналар кертеме** | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Үткәрелгән ачык аукцион нәтиҗәләре буенча | | | | | | | | | |
| Конкурс нәтиҗәләре буенча | | - | 20 | 7 | 865,35 | 121149,00 | 101946,88 | 18172,35 | 1029,77 |

### 8. Профилактик исәптә торучы балалар өчен палаткалы лагерьда махсуслаштырылган смена

| Стационар БСЛ атамасы | Үткәрү территориясе | БСЛ балансга тотучының исеме | Кеше саны* | Көн саны* | Бер көнгә бер бала өчен урын | Юлламаның норматив бәясе | Бюджеттан субсидияләр** | Ата-аналар кертеме** | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Үткәрелгән ачык аукцион нәтиҗәләре буенча | | | | | | | | | |
| Конкурс нәтиҗәләре буенча | | - | **10** | **7** | **1056,82** | **73977,40** | **73977,40** | **0** | **0** |

### 9. Авыр тормыш һәм социаль куркыныч хәлдәге балалар өчен стационар лагерьда смена

| Стационар БСЛ атамасы | Үткәрү территориясе | БСЛ балансга тотучының исеме | Кеше саны* | Көн саны* | Бер көнгә бер бала өчен урын | Юлламаның норматив бәясе | Бюджеттан субсидияләр** | Ата-аналар кертеме** | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Үткәрелгән ачык аукцион нәтиҗәләре буенча | | | | | | | | | |
| Конкурс нәтиҗәләре буенча | | - | **5** | **21** | **876,05** | **91985,25** | **91985,25** | **0** | **0** |

### 9. Авыр тормыш һәм социаль куркыныч хәлдә булган балалар өчен стационар лагерьда смена

| Стационар БСЛ атамасы | Үткәрү территориясе | БСЛ балансга тотучының исеме | Кеше саны* | Көн саны* | Бер көнгә бер бала өчен урын | Юлламаның норматив бәясе | Бюджеттан субсидияләр** | Ата-аналар кертеме** | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Үткәрелгән ачык аукцион нәтиҗәләре буенча | | | | | | | | | |
| Конкурс нәтиҗәләре буенча | | - | **5** | **7** | **876,05** | **30661,75** | **30661,75** | **0** | **0** |

**Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан балалар һәм яшьләр ялын оештыруны тәэмин итүгә субсидияләр**

| Күрсәткеч атамасы | Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән субсидиеләр (сум) |
|---|---|
| Муниципаль районның дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең, хуҗалык субъектларының балалары арасыннан бер балага Татарстан Республикасында балаларның ялын оештыруны тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативы (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш) | 1000,00 |

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «30» 12 2021 №333 карарына 4 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесе
Ф.И.А.И. әнисе__________________________
__________________________________________
Әнисенең эш урыны ____________________
__________________________________________
Ф.И.А.И. әтисе__________________________
__________________________________________
Әтисенең эш урыны
______________________
__________________________________________
Баланың законлы вәкиленең Ф.И.А.И.
__________________________________________
__________________________________________
Индекс күрсәтелгән өй адресы (теркәлү урыны буенча ________________________
__________________________________________
(чын яшәү вакыты)
__________________________________________
__________________________________________
__________________________________________
Элемтә өчен телефоннар (йорт, эш, хезмәт)
__________________________________________

**Гариза**

Балага юллама бирүегезне сорыйм ________________________________________
*(Ф.И.А.И. баланыкы тулысынча)*
______________________________________________________________________________
Көн, ай, туган ел__________________________ җенес _____________________
Туу турында таныклык (паспорт) сериясе ______________ № ____________________
Бирү датасы _________________________________________________________________,
Бала укый торган гомуми белем бирү учреждениесенең исеме
______________________________________________________________________________
Баланы укыту сыйныфы _________________________________,
Лагерьга ___________________________________________________

Өстәмә мәгълүмат түбәндәге категориягә керүче балалар өчен (кирәклесен ассызыкларга):
- ятим,
- ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар,

- күп балалы гаиләләрдән,
- тулы булмаган гаиләләрдән,
- качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр гаиләләреннән,
- коралы конфликтларда зыян күргән хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләреннән,
- балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиядә исәптә торучылар.

**Гаризага теркәп бирелә:**
*- туу турында таныклык күчермәсе яки бала паспорты*
*- баланың уку урыныннан белешмә*
*- бер әти-әнинең эш урыныннан белешмә*
*- мед. полис күчермәсе*
*- Прививкалар турында медицина белешмәсе*
*- йогышлы авыруларның булмавы турында медицина белешмәсе*
*- анализ нәтиҗәләре*
*- бер әти-әнинең паспорт күчермәсе*

«____» __________________20__ ел Имза ________________________